# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**Дүртенче чакырылыш егерме алтынче утырыш**

**Олы Нырсы авылы** **№ 101** **07.02.2024 ел**

Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Советының 2023 елның 25 сентябрь №88 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын тоту кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2024 елның 17 гыйнварындагы 09/13-09/203 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Советының 2023 елның 25 сентябрь №88 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын тоту кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәреш кертергә, күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын тоту кагыйдәләренең 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«2.5. Терлек азыгын, тиресен һәм компостын туплау хайваннар йорты территориясендә генә рөхсәт ителә, анда янгынга каршы нормалар, санитария, ветеринария һәм эстетик нормалар һәм таләпләр үтәлергә тиеш.

Мөгезле эре һәм мөгезле вак терлек, һичшиксез, биркаланырга тиеш (К51 11.10.04г.п. 14. боерыгын кар. Ветеринария идарәсе).

Күзәтүчесез булган, шулай ук номеры булмаган мөгезле эре һәм вак терлек сукбай булып санала һәм кире тотылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Олы Нырсы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Гиниятов